**ГЛАВА СОВЕТА СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422622 с. Сокуры,
ул. Державина , д.12 а
тел: 4-07-83

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**

**РАЙОНЫ СОКУРЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422622 Сокуры авылы,
Державино урамы, 12а нчы йорт,
тел: 4-07-83

---

**№ 02** **2019 елның 13 июненнән**

# КАРАР

**Социаль юнәлешле янгын сүндерү җәмәгать берләшмәләренә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә һәм сакчыларга өстәмә ярдәм чаралары турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә», «Ирекле янгын саклау турында» 2011 елның 6 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасының 01.08.2011 № 48-ТРЗ «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» гы Законы нигезендә Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегендә ирекле янгын сүндерү хезмәтен үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында:

1. Ирекле янгын сүндерү командаларына һәм ирекле янгын дружиналарына түбәндәге ташламалар һәм ярдәм чаралары бирергә: гадәттән тыш режимда янгыннарны сүндергәндә һәм авария-коткару эшләрен үткәргәндә төп эш урынынннан отгуллар бирү буенча ташлама вәзгыятьне; янгыннарны сүндергәндә һәм авария-коткару эшләрен үткәргәндә ирекле янгын сүндерү хезмәте әгъзаларын гадәттән тыш режимда туклану белән тәэмин итәргә.

2. Ирекле янгын сүндерүчеләр эшчәнлегенә матди һәм мораль стимул бирергә. Ирекле янгын сүндерүчеләрне янгыннарны профилактикалауда һәм (яки) сүндерүдә һәм авария-коткару эшләрен үткәрүдә түләүсез нигездә катнашучы мораль һәм матди кызыксындыру буенча түбәндәге чараларны билгеләргә:

а) муниципаль берәмлек Башлыгының Рәхмәтен белдерү;

б) кыйммәтле бүләкләр тапшыру;

в.) муниципаль берәмлек Башлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләү;

г.) Мактау Китабына кертү. Предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләре үз акчалары хисабына, ирекле янгын сагы иҗтимагый берләшмәләренә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр бирә алалар.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

**Сокуры авыл җирлеге Башлыгы** **А. А. Новиков**